**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Рантамак торак пунктында
2026 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

2025 елның 27 ноябре № 2

20.03.2025 елның № 33-ФЗ «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законының 45, 69 нчы маддәләренә туры китереп , «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлегенең Рантамак торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең Рантамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, хәрби хезмәт итүче, контракт нигезендә хәрби хезмәт итүче, мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган гражданнардан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Рантамак торак пунктында кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү) ;

2) Рантамак торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклый торган яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

3) Рантамак авылында хуҗасыз хуҗалыкларны киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу

4) Рантамак авылында җәйге вакытта территорияне чабу (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

5) Рантамак авыл эчендәге юлларны ремонтлау (транспорт хезмәтләре күрсәтү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

6) Беларустракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, йөртүчегә хезмәт хакы түләү);

7) трактор өчен асылмалы җайланмалар сатып алу.

8) кое тирәсен коймa белән әйләндереп алу

3. Җыен нәтиҗәләрен Рангазар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге башлыгы Р.Н.Кыямов